# КАРАР

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районыны Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылында 2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында**

**20 ноябрь, 2024 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь торак пунктында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлардан); 1 төркем инвалидларыннан; 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау комплектлау материаллары сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, эш өчен шартнамә буенча түләү, смета төзү һәм түләү, Ямбулат-Пустошь авылында урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре; урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, эш өчен шартнамә буенча түләү, смета төзү һәм түләү, Ямбулат-Пустошь авылында урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы җиһазлар һәм комплектлау әйберләрен сатып алу, ташу, урнаштыру һәм карап тоту, смета документларын эшләү һәм түләү, эш өчен шартнамә буенча түләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Ямбулат-Пустошь авылында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүнең башка төрләре);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (элмә такта сатып алу һәм урнаштыру, җәен территориянең печәнен чабу, торак пункт территориясен төзекләндерү, материаллар сатып алу һәм ташу; килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм түләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Ямбулат-Пустошь авылы торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларына вак таш җәю, вак таш салып, чокырларны ремонтлау, вак таш һәм материаллар сатып алу, ташу һәм вак таш салу, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм түләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; кышын кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; күперне төзү һәм

ремонтлау, су үткәргеч торба урнаштыру; Ямбулат-Пустошь авылы юлларын төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (чишмә территориясен төзекләндерү); койма һәм баскычны ремонтлау һәм буяу, материаллар сатып алу һәм ташу; килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм түләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Ямбулат-Пустошь авылында җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) төзү, ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү (һәйкәлне төзү, төзекләндерү һәм карап тоту, яздырып граниттан мемориаль такталар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм түләү, килешү буенча эш өчен түләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Ямбулат-Пустошь авылында һәйкәлләрне төзү һәм аларга якын территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (җәяүлеләр күперен төзү, ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм түләү, килешү буенча эш өчен түләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Ятмас-Дусай авылында җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрне ремонтлауның башка төрләре).

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan адресы буенча бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы: А.И. Шаймарданова

ОГРН 1021607753155
ИНН 1623001685